ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Гаилә кодексының $141^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 29 октябрендә
кабул ителде

## 1 статья

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының $141^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә «һәр опекага алынган бала өчен 3 000 сум күләмендә билгеләнә» сүзләрен «һәр опекага алынган бала өчен 8 641 сум күләмендә билгеләнә һәм ай саен түләнә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 – 5 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Педагогик һәм (яисә) медицина белеме булган опекуннарга яисә попечительләргә, опекада яисә попечительлектә торучы балалар санына бәйсез рәвештә, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән түләүгә 13 546 сум күләмендә өстәмә билгеләнә.

4. Балага яисә балаларга берничә опекун яисә попечитель билгеләнгән очракта, түләү, шул исәптән аңа өстәмә, бер опекунга яисә попечительгә билгеләнә һәм түләнә. Түләү, шул исәптән аңа өстәмә, берничә опекун яисә попечитель арасында алар билгеләгән пропорциядә бүленергә мөмкин. Түләүне, шул исәптән аңа өстәмәне, опекуннар яисә попечительләр арасында үзара килешеп бүлү опеканы яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турындагы шартнамәдә күрсәтелә.

5. Опекуннарга яисә попечительләргә түләү, шул исәптән аңа өстәмә, чыгымнары Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов




Казан, Кремль
2025 ел, 11 ноябрь
№ 75-ТРЗ